## Җыр-моң – халкыбызның тере рухы ул

Тукаебыз җырларда «халык күңеленең мәңге тутыкмас саф рәушан көзгесе»н күрә, ягъни халык рухын, мәңге тере сакланачак җан тарихы чагылышын таба шул кадерле көзгедә. «Уклар да аталмаган, туплар да ваталмаган» мөкатдәс халык җырларын ничек төгәл бәяли алган бит бөек шагыйребез…

Без, шагыйрьләр, бүген дә әнә шул «рәушан көзге»гә еш карарга, милләтнең моң көчен бүгенге көн күзлегеннән үлчәп чамаларга, аның мәңгелегенә кабат-кабат иман китереп, аны сакларга, антыбызны һаман да яңартып торырга тиешбез дип беләм. Бу — Тукайлар васыятенә тугры калу, рухны пакьләү, шик-шөбһәләрдән арыну өчен дә кирәктер. Яшәтүче олуг көч ул — татар җыры, татар моңы!

Бәхетебезгә, узган гасырның бөек җырчылары әнә шул моңны яшәтү миссиясен нәкъ Тукайча аңлап, халыкны, яңа буыннарны, димәк, иҗатчыларны да шул сыналган изге юлда, милли мәктәптә тәрбияләделәр дә. Әйе, гаҗәеп милли моңлы җырчыларыбыз яшәп китте безнең арада: Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйрова, Мәгафур Хисмәтуллин, Хәйдәр Бигичев, Фәридә Кудашевалар һәм, бәхеткә, әле дә тере легенда булып яшәүче Илһамнар, Әлфияләр… Без шагыйрьләр дә аларга мең-мең бурычлыбыз. Үзебезнең буынны гына әйтмим, яшьрәкләр дә… Сез аларның репертуарындагы борынгы моң үрнәге булган озын җырларны алып кара-

гыз да бөек җырчыларның алар башкаруындагы тиңсез алымнарын чамалагыз. Һәркайсында аерым осталык, мелизмнар, бормалар, тавышның мөмкинлеге сыналу, иркенлек, киңлек көче... Кабатланырмы шундый алтын чор? Бүген дә халык җырларын башкаруда, хәтта репертуарда яңалар белән баетуда «үз җыры»н эзләү-табуда Мирсәетләр, Фердинандлар нәкъ менә шушы мәктәп тәҗрибәсенә таянып, аларны дәвам итә бит. Филүс, Айгөл, Ришатлар да... Йа Раббым, дим, аерма аларны әлеге изге юлларыннан! Халкыбызның җанын, рухын саклау юлында булсын алар, шул миссиянең әйдаманнары ролен үтәсеннәр.

Бу язганнарым, дога һәм өметләрем, әлбәттә, аһәңсазлар белән шагыйрьләр тудырган бүгенге яңа, Тукай язганча, «сонгый» җырларга да карый.

Аллага шөкер, бөек шагыйрьләребезнең сүзләренә язылган җырлар да узган гасырдан яңасына исән-сау кичеп чыктылар. Н. Исәнбәт, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан, С. Хәким җырларын да без бит милли хәзинәбездән саныйбыз. Димәк, яңа заман җырларыннан да шундый югарылык, халыкчанлык, шигърилек сорала. Хәтта таләп ителә! Чөнки җырларыбыз бүген дә нәкъ шул «рәушан көзге»безнең исән-сау дәвамы. Болгардан исән-сау безнең чорга килеп җиткән көзге турында, кошлар сурәте белән бизәлгән, Сак-Сокларны хәтерләткән тарихи табылдык турында Сибгат ага Хәким язган шигырь дә хәтердә. Моң кошлары алар! Тарихи аң һәм хәтер ияләре!

Җырларны туплап, җыйнап, матур бер китап хәлендә халыкка, моңга һәрчак сусаган укучыга кайтарып бирү йә аны актару, уку мизгелләре — илаһи бер вакыт, мәңгелек моң белән кабат очрашу бәхете ул, дусларым!

РӘДИФ ГАТАШ,<br>
*Татарстан Республикасының*<br>
*халык шагыйре*

# Туган тел

*Габдулла Тукай*
сүзләре

*Татар халык*
көе

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

# Авылым урамнары

*Хәниф Хөснуллин*
сүзләре

*Илгиз Закиров*
музыкасы

Таллары шаулый җилләрдә,
Көйли күрешү көен.
И минем туган авылым,
И минем туган өем.

К у ш ы м т а:

Оныта алмыйм, онытмыйм
Авылым урамнарын —
Хәтер булып еракларга
Сузыла торганнарын.

Үз итеп яшәсәм дә мин
Илемнең башка ягын,
Авылымда көтеп тора
Күптәнге бала чагым.

К у ш ы м т а.

Рәхмәтемне белдерергә
Сүзләрем җитми минем.
Кырларың, урамнарың күк,
Күңелең иркен синең.

К у ш ы м т а.

# Агыйдел каты ага

*Татар халык җыры*

Агыйделдә йөрсәң иде,
Камыштан көймә үреп;
Былбыл булып, гөлгә кунып
Сөйләшсәң иде күреп.

К у ш ы м т а:

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем килә.

Аклы күлмәкнең җиңе тар,
Җиң очында хаты бар;
Хатын укып карагачтын,
«Сөям» дигән сүзе бар.

К у ш ы м т а:

Агыйдел күпере,
Чуенмы әллә, чылтырый;
Каш астында ике күзе
Энҗе кебек елтырый.

Агыйделдән көймә килә
Кылдай нечкә эз белән;
Җаным, нигә хәтерең калды
Уйнап әйткән сүз белән?!

К у ш ы м т а:

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем килә.